КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2021 ел, 20 гыйнвар г.Казань № б-79

Татарстан Республикасы Президентының «2021 елны Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итү турында» 2020 елның 5 октябрендәге ПУ-653 номерлы Указын үтәү йөзеннән:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын уздыру буенча төп чараларның республика планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнарына Планны гамәлгә ашыруда катнашуны тәкъдим итәргә.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына Планны мәгълүмати яктан алып барылышын тәэмин итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 20 гыйнвар, 6-79 нчы
боерыгы белән расланды

2021 елда Татарстан Республикасында Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын үткәрү буенча төп чараларның республика планы

| Т/с | Чара исеме | Үткәрү датасы | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Халыкара туган тел көненә багышланган айлык, шул исәптән: төрле халыклар кинематографистлары тарафыннан туган телләрдә төшерелгән фильмнарны күрсәтеп, Татарстан Республикасы халыкларының «Панорама» кинофестивален ачу;<br>Татарстан Республикасында яшәүче халыклар катнашында концерт программалары;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә Халыкара туган тел көненә багышланган тематик программалар | 20 гыйнвар – 21 февраль | ТР МһФМ[1], ТР ММ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ФА, ТХА (килешү буенча), БТК (килешү буенча), ТР ЯБ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча), «Татаркино» ТР ДБМУ (килешү буенча) |
| 2. | Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елын ачуга багышланган бәйрәм чарасын оештыру һәм үткәрү | 29 гыйнвар | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 3. | Мари халкының «Шорык йол» традицион йола бәйрәмен үткәрү | гыйнвар | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), «ТР марилары ММА» ТИО (килешү буенча) |

[1] Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 18 биттә

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 4. | Керәшен мәдәниятенең Я.Е.Емельянов исемендәге «Җәшнә, кояш, җалтыра» республика конкурс-фестивале | гыйнвар – март | ТР ММ, Емельянов ис. МҮ (килешү буенча) |
| 5. | Яшь журналистларның «Каурый каләм» бөтенроссия конкурсы | 1 февраль – 19 май | КФУ (килешү буенча) |
| 6. | Казан университетында журналистика факультетының беренче деканы Ф.И.Әгъзамов истәлегенә багышланган «Әгъзамов укулары» халыкара фәнни-гамәли конференциясе | 19 февраль | КФУ (килешү буенча) |
| 7. | Аспирантлар, студентлар һәм укучыларның «Төрки лингвокультурология: проблемалар һәм перспективалар» XII Халыкара фәнни-гамәли конференциясе | 19 февраль | КФУ (килешү буенча) |
| 8. | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының һәм Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасының Миллиара һәм диниара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү комиссиясенең «Россия Федерациясенең этномәдәни һәм тел күптөрлелеген саклау һәм тәэмин итү – гомумроссия бердәмлеген ныгытуның мөһим факторы» дигән уртак утырышы | февраль | ТР ИП (килешү буенча) |
| 9. | Этномәдәни компонентлы белем бирә торган мәктәпләр һәм якшәмбе мәктәпләре укучыларының республика фестивале | февраль | ТР МһФМ, ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 10. | Буддизм динен таратучы халыкларның, шулай ук көнчыгыш дине һәм фәлсәфәсе мәсьәләләре белән кызыксынучы халыкларның бердәмлеге көненә багышланган чаралар кысаларында үткәрелә торган «Сагаалган – 2021» бәйрәме атнасы | февраль | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), «Казан ш. бурятлары ММА» ҖИО (килешү буенча) |
| 11. | Татар шагыйре, Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең тууына 115 ел тулуга багышланган чаралар кысаларында «Җәлил укулары» III Халыкара сәнгатьчә укучылар конкурсының гала-концерты | февраль | ТР ММ, ТР МһФМ, БТК (килешү буенча), ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 12. | Татарстан Республикасының массакүләм мәгълүмат чараларында этносара һәм конфессияләр арасындагы мөнәсәбәтләр мәсьәләләрен иң яхшы яктыртуга республика журналистлар конкурсын оештыру | февраль – сентябрь | «Татмедиа» РА |
| 13. | «Күпкырлы Россия» Бөтенроссия журналистлар конкурсын үткәрү | февраль – октябрь | «Татмедиа» РА |
| 14. | «Россия халыкларының милли бәйрәмнәре» бөтенроссия фотоконкурсын үткәрү | февраль – ноябрь | «Татмедиа» РА |
| 15. | Польша композиторы һәм пианисты Фредерик Шопенның 211 еллыгына багышланган балалар музыка фестиваль-конкурсын оештыру | 1 март | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), «Казан ш. Поляклар» ҖИО (килешү буенча) |
| 16. | «XVII – XX гасыр Идел буе һәм Урал буе халыкларының этносоциаль төркемнәрен формалаштыру һәм трансформацияләү» бөтенроссия фәнни конференциясе | март | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 17. | «Масленица» славян мәдәнияте бәйрәмен үткәрү | март | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 18. | «Нәүрүз» төрки халыклар бәйрәмен үткәрү | март | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 19. | «Туган телләр укытучыларының мастер-классы» бөтенроссия конкурсы | март | ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 20. | «Татарстан Республикасында туган удмурт телендә белем һәм тәрбия бирә торган балалар мәгариф оешмасының иң яхшы тәрбиячесе» республика конкурсы | март | ТР МһФМ, ТХА (килешү буенча) |
| 21. | «Татарстанда рус мәдәнияте» журналын бастырып чыгару (ике чыгарылыш) | май – ноябрь | ТР ММ, ТР РММБ (килешү буенча) |
| 22. | «XVIII – XX гасыр бөек татар мәгърифәтчеләренең педагогик мирасы» халыкара семинары | 23 – 24 апрель | КФУ (килешү буенча) |
| 23. | Туган тел көненә һәм бөек татар шагыйре Г.Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланган тантаналы чара Г.Тукай исемендәге Татарстан Республикасы дәүләт премиясен тапшыру | 26 апрель | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 24. | Күпмилләтле якшәмбе мәктәпләренең «Йөрәкне мәхәббәт белән тулыландырыйк» фестивале | апрель | ТР МһФМ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 25. | Бөек татар шагыйре Г.Тукайның тууына 135 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция | апрель | ТР ФА, ТР МһФМ, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 26. | Туган татар теленә тәрҗемә ителгән укыту методик комплектларын һәм туган тел буенча укыту-методик комплексларны федераль дәреслекләр исемлегенә кертү | апрель | ТР МһФМ, «Татмедиа» РА, ТКН (килешү буенча) |
| 27. | Габдулла Тукай исемендәге Халыкара сәнгатьчә укучылар конкурсы | апрель | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, ТР ТЭБ (килешү буенча) |
| 28. | Туган тел декадасын оештыру һәм үткәрү, шул исәптән:<br>татар теле буенча халыкара олимпиада;<br>«Татар теленең виртуаль кабинеты» конкурсы | апрель | БТК (килешү буенча) |
| 29. | Яшь шагыйрьләр, язучылар һәм драматургларның «Илһам» бөтенроссия фестивале | апрель | ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 30. | Беларусь һәм Россия халыкларының берләшү көнен үткәрү | апрель | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), «Спадчына» ҖИО (килешү буенча) |
| 31. | Чуваш җырын башкаручыларның «Чуваш сандугачы» республика конкурсы | апрель | «ТР Чуваш ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 32. | «Җәмгыять үсешенең яңа этабында телләрне, милләтара һәм конфессияара татулыкны саклау» халыкара конференциясе | апрель | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР МһФМ, ХДЙ (килешү буенча) |
| 33. | Интернет массакүләм мәгълүмат чаралары өчен «Теле барның юлы бар» республика журналистлар конкурсы | апрель – август | «Татмедиа» РА |
| 34. | Бөек Җиңү көненә багышланган СССР халыклары телләрендәге сугыш еллары плакатлары һәм газеталары күргәзмәсе | май | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР Архдәүлком, ТР ЖБ (килешү буенча) |
| 35. | «Каравон» рус халык бәйрәме | май | ТР ММ, ТР Лаеш МР (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |
| 36. | «Бәрмәнчек бакчасы» керәшен православие мәдәнияте фестивале | май | ТР ММ, «Бермәнчек» КДФА (килешү буенча), ТР керәшеннәре ИО (килешү буенча) |
| 37. | Славян язуы һәм мәдәнияте көненә багышланган «Кириллица» балалар-яшүсмерләр хор иҗаты фестивале | май | РПЧ ТМ (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |
| 38. | «Дуслык учагы» төбәкара фестивале | май | ТР Балтач МР (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 39. | Казан (Идел буе) федераль университеты базасында би- һәм полилингваль нигездә педагогик кадрлар әзерләүне тәэмин итү | май, декабрь | ТР МһФМ |
| 40. | Россия Федерациясе субъектлары мәгарифе эчтәлеге этномәдәни (татар) компонентлы булган белем бирү оешмалары җитәкчеләре һәм татар теле һәм әдәбияты укытучылары өчен квалификация күтәрү курслары | май, декабрь | ТР МһФМ |
| 41. | Рус теле көненә һәм А.С.Пушкин тууының 222 еллыгына багышланган тантаналы чара | 6 июнь | ТР ММ, ТР ЯБ (килешү буенча) |
| 42. | Рус теле көненә багышланган чаралар, шул исәптән язучылар бергәлеге белән иҗади очрашулар, сәнгатьчә укучылар конкурслары, китап күргәзмәләре, семинарлар, ачык дәресләр | 6 июнь | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча), ТХА (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |
| 43. | Төрки халыкларның «Нәүрүз» XV Халыкара театр фестивале | 7 – 13 июнь | ТР ММ, Камал ис. ТДАТ (килешү буенча) |
| 44. | Россия көненә багышланган чаралар үткәрү, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасының сәнгать осталары катнашында бәйрәм концерт программалары;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә балаларга һәм яшьләргә патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән тематик чаралар | 12 июнь | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТХА (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 45. | «Таба» яшьләр этномузыка фестивале | 12 июнь | ТР ЯЭМ, ТХЯА (килешү буенча) |
| 46. | Идел Болгарының Ислам динен рәсми кабул итү көненә багышланган «Изге Болгар җыены» тантаналы чарасы | июнь | ТР ММ, БТК (килешү буенча), ТР МДН (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 47. | «Семык» республика мари мәдәнияте бәйрәме (аерым план буенча) | июнь | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), «ТР марилары ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 48. | «Балтай» республика мордва (эрзя) мәдәнияте бәйрәме (аерым план буенча) | июнь | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), «ТР мордвалары ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 49. | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә «Сабантуй» татар халык бәйрәме (аерым план буенча) | июнь | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 50. | «Гырон быдтон» республика удмурт мәдәнияте бәйрәме (аерым план буенча) | июнь | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), «ТР удмуртлары ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 51. | «Идел буе һәм Урал буеның музыка фольклоры: Казан консерваториясенең экспедиция язмаларыннан» (Татарстан Республикасының Тәтеш районы мордвалары җырлары, шаран марилары җырлары) хрестоматиясе чыгарылышларын әзерләү һәм бастырып чыгару | июнь | Җиһанов ис. КДК (килешү буенча) |
| 52. | Үзәк башкарма комитетының һәм Татарстан АССР Халык комиссарлары советының татар теленең дәүләт статусы турындагы декретын кабул итүнең 100 еллыгына багышланган «Милли төбәкләрдә тел сәясәте һәм тел ландшафты» бөтенроссия фәнни конференциясе | июнь | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 53. | Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Мөслим авылында XI Бөтенроссия авыл Сабантуе | июнь | ТР Мөслим МР (килешү буенча), ТР ММ |
| 54. | «Татарстан халыклары мәдәнияте калейдоскопы» проекты: чуваш, удмурт, мари, мордва халыклары күпләп яшәгән Татарстан Республикасы торак пунктларына аларның матди | июнь – сентябрь | ТР ФА |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | һәм рухи мәдәниятен өйрәнү буенча комплекслы экспедицияләр;<br>Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче Идел буе халыкларының матди һәм рухи мәдәниятен өйрәнү буенча комплекслы экспедицияләр йомгаклары буенча төбәкара түгәрәк өстәл;<br>«Татарстан халыклары мәдәнияте калейдоскопы» коллектив монографиясен әзерләү һәм бастырып чыгару | ноябрь<br><br><br>ноябрь | |
| 55. | Татарстан Республикасыннан, Башкортостан Республикасыннан һәм Удмуртия Республикасыннан удмурт мәктәпләре укучыларының, студентлар һәм эшләүче яшьләрнең «БиГерд» төбәкара форумы | июнь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 56. | «Яңа чынбарлык шартларында тел коммуникацияләрен трансформацияләү» халыкара фәнни-гамәли конференциясе | июнь | КФУ (килешү буенча) |
| 57. | Державин шигърият фестивале | 14 июль | ТР ММ, ТР ЯБ (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |
| 58. | IT BILER FORUM «Сәләт» халыкара яшьләр белем бирү форумы | 14 – 18 июль | ТР ЯЭМ, ТР ФА |
| 59. | «Иван Купала» республика славян мәдәнияте бәйрәме (аерым план буенча) | июль | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), «Украина ММА» ТИО (килешү буенча), «Спадчына» ҖИО (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 60. | «Уяв» республика чуваш мәдәнияте бәйрәме | июль | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), «ТР Чуваш ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 61. | «Питрау» республика керәшен мәдәнияте бәйрәме | июль | ТР ММ, ХДЙ (килешү буенча), ТР керәшеннәре ИО (килешү буенча) |
| 62. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләрендә диктантлар һәм иншалар язу буенча иҗтимагый акцияләр үткәрү | июль | ТХА (килешү буенча), БТК (килешү буенча), ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТР ММ |
| 63. | Татарстан халыклары ассамблеясе тарихы турында китап, шулай ук Татарстан халыклары ассамблеясе һәм Татарстан халыклары Дуслык йорты турында альбом бастырып чыгару | июль | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 64. | «Татар теле һәм мәдәнияте» белешмә китабын әзерләү һәм бастырып чыгару (татар, рус һәм инглиз телләрендә) | июль – сентябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 65. | Россия Федерациясе Дәүләт флагы көненә багышланган чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә иҗади мастер-класслар һәм конкурслар белән тематик чаралар, концерт программалары | 22 август | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 66. | Муса Җәлилне җәзалауга 77 ел булу уңаеннан аның һәйкәленә чәчәкләр салу | 25 август | ТР ММ, ТР ЯБ (килешү буенча) |
| 67. | Республика «ЭтноСтартапФорум» | 28 – 30 август | ТР ЯЭМ, ТХЯА (килешү буенча), ТР Сәнәгать министрлыгы, ТР ИҮА, ТР ММ, ТР Урмхуҗмин, ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 68. | Татарстан Республикасы көненә багышланган чаралар үткәрү, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы сәнгать осталары катнашында тантаналы чара;<br>Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә массакүләм мәдәни программалар | август | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТХА (килешү буенча), БТК (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 69. | «Мәдәниятләр мозаикасы» республика этноконфессиональ фестивалын үткәрү | август | ТР ММ, ТР ЯЭМ, ТР МһФМ, ТХА (килешү буенча) |
| 70. | «Түгәрәк уен» бөтенроссия татар фольклоры фестивален үткәрү | август | ТР ММ, БТК (килешү буенча), Татмәдресурсүзәге (килешү буенча) |
| 71. | «Казанда көнчыгыш базары» фестивале | август | ТР ММ, Ваһапов ис. Фонд (килешү буенча) |
| 72. | «Татарстан халыклары кухнясы» төбәкара конкурс-фестивален үткәрү | август | ТР ЯЭМ, ТР ММ, ТХА (килешү буенча) |
| 73. | Журналистлар һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен татар дөньясының тормышын һәм эшчәнлеген иң яхшы яктыртуга «Татар рухы һәм каләм» бөтенроссия конкурсы | август – ноябрь | «Татмедиа» РА, БТК (килешү буенча) |
| 74. | Дагестан бердәмлеге көненә багышланган «Дагестан халыклары мәдәнияте мозаикасы» фестивале | 18 сентябрь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), «Дагестан» ТИО (килешү буенча) |
| 75. | «Амадин тавышы» төбәкара туган телдәге җырлар конкурс-фестивале | 21 сентябрь | ТХЯА (килешү буенча), ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 76. | «Без бергә!» күчмә республика фестивале | сентябрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 77. | Халыкара яһүд музыкасы фестивале | сентябрь | ТР ММ, «ТР Яһүдлар ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 78. | «Татар традицион музыка уен кораллары мәдәнияте» фәнни җыентыгын әзерләү һәм бастырып чыгару | сентябрь | Җиһанов ис. КДК (килешү буенча) |
| 79. | Казан шәһәренең «Күпмилләтле якшәмбе мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесендә һәм аның муниципаль берәмлекләрендәге бүлекләрдә уку дәресләрен үткәрү | сентябрь – май | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча), ТР МһФМ |
| 80. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган «Туган киңлекләр» I Бөтенроссия пленэры | сентябрь – октябрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ММ, ТР РБ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 81. | Фин-угор халыкларының республика фестивале | сентябрь – октябрь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча) |
| 82. | «Безнең йорт – Татарстан» республика этномәдәни фестивален үткәрү | сентябрь – ноябрь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР МһФМ, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 83. | Рус язучысы – Казан университетының беренче студенты С.Т.Аксаков бюстын ачу тантанасы | 1 октябрь | ТР ММ, КФУ (килешү буенча), ТР РММБ (килешү буенча) |
| 84. | TurkLang төрки телләрне компьютер нигезендә эшкәртү буенча халыкара конференция | 18 – 19 октябрь | ТР ФА |
| 85. | Студентлар һәм мәктәп укучылары өчен славян язуы һәм мәдәнияте көненә багышланган «Рус теле һәм славян дөньясы» фәнни-гамәли конференциясе | 20 октябрь | ТР МһФМ, КФУ (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 86. | Мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч мәктәп яшендәге балаларны чуваш халкы мәдәниятенә җәлеп итү максатларында мәктәп укучыларының «АТАЛАН» милли белем бирү форумы | октябрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 87. | «Балаларны туган (татар, чуаш, удмурт, мари, мордва) телендә укытуны һәм тәрбияләүне оештыру буенча иң яхшы балалар бакчасы» республика конкурсы | октябрь | ТР МһФМ |
| 88. | «Россия халыкларының туган телләре: хәзерге заман мәгарифе шартларында телләр укытуның актуаль мәсьәләләре» республика форумы | октябрь | ТР МһФМ, ТР ФА |
| 89. | «Россия Федерациясенең архив фондында туган телләрдәге документлар» бөтенроссия фәнни конференциясе | октябрь | ТР Архдәүлком |
| 90. | Халык язучылары һәм шагыйрьләре катнашында «Поэзии чарующие строки» бөтенроссия фестивале (төрле телләрдә) | октябрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ЯБ (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 91. | «Республикалар кул биреп исәнләшү» әдәби-шигъри конкурс-фестивале | октябрь | ТР ММ, ТР РММБ (килешү буенча) |
| 92. | Мәктәп укучылары өчен «Туган тел» республика әдәби конкурсы (төрле телләрдә) | октябрь | ТР МһФМ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ЯБ (килешү буенча), ТР ЖБ (килешү буенча) |
| 93. | «Гаилә тарихында гасыр кайтавазы – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме | октябрь | ТР Архдәүлком, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 94. | Татарстан Республикасының белем бирү учреждениеләре өчен туган телләрне саклау һәм үстерү мәсьәләләре буенча республика семинарлары һәм лекцияләре | октябрь | ТР МһФМ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 95. | Россия Федерациясе субъектларында туган тел һәм әдәбият укытучылары делегацияләренең күчмә семинарларын, туган (татар) теле һәм әдәбияты укытучылары өчен төбәкара вебинарлар үткәрү, татар-мәгариф көннәрен оештыру һәм үткәрү (аерым план буенча) | октябрь – ноябрь | ТР МһФМ, ТР ФА, КФУ (килешү буенча) |
| 96. | «Таба» яшьләр этнопроектлары форумы | 1 – 4 ноябрь | ТР ЯЭМ, ТХЯА (килешү буенча) |
| 97. | «Казан-Экспо» халыкара күргәзмә үзәгендә Халыклар бердәмлеге көненә багышланган тантаналы чара үткәрү | 4 ноябрь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), БТК (килешү буенча) |
| 98. | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары катнашында Татарстан Республикасы Конституциясе көненә багышланган тантаналы чара | 6 ноябрь | ТР ДС (килешү буенча), ТР ММ, «Татмедиа» РА |
| 99. | «Нигъмәтов укулары. Идел буеның күпмәдәниятле белем бирү киңлеге: интеграция юллары һәм формалары» III Халыкара фәнни-педагогик конференциясе | 12 – 13 ноябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 100. | «Күпмилләтле дәүләт шартларында туган телләрне саклау һәм үстерү: проблемалар һәм перспективалар» халыкара фәнни-гамәли конференциясе | 18 – 21 ноябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 101. | «Мәдәниятләр диалогында музыка. Идел буе һәм Урал буе халыкларының традицион музыка мәдәнияте» халыкара фәнни-гамәли конференциясе | 24 – 26 ноябрь | Жиһанов ис. КДК (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 102. | Туган тел һәм әдәбият укытучыларының «Халыкның бердәмлеген ныгыту факторы буларак мәдәниятара коммуникация» төбәкара форумын оештыру | 29 ноябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 103. | Татарстан Республикасы Дәүләт флагы көненә багышланган чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасының белем бирү оешмаларында мәгълүмати сыйныф сәгатьләре, танып-белү семинарлары, Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә иҗади мастер-класслар һәм конкурслар белән тематик чаралар, концерт программалары | 29 ноябрь | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 104. | Н.Д.Мусинаның «Нократ арты (ар) удмуртларының бию фольклоры – Татарстан Республикасы халыкларының матди булмаган мәдәни мирасы» монографиясен бастырып чыгару | ноябрь | ТР ФА |
| 105. | «Әпипә» бөтенроссия телевизион татар халык биюе конкурсын үткәрү, шул исәптән бию биергә өйрәтү буенча мастер-класслар үткәрү | ноябрь | БТК (килешү буенча) |
| 106. | «Чыганакларга сәяхәт» республика конкурсы | ноябрь | ТР Турдәүлком |
| 107. | «Фин-угор дөньясының музыка мәдәнияте: традицияләр, заманчалык, перспективалар» дигән мәкаләләр җыентыгын әзерләү һәм бастырып чыгару | ноябрь | Жиһанов ис. КДК (килешү буенча) |
| 108. | «Сәйяр» республика театр-конкурсы | ноябрь | ТР МһФМ |
| 109. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган Казан халыкара лингвистика саммиты | ноябрь | КФУ (килешү буенча) |
| 110. | Россия Федерациясе Конституциясе көненә багышланган чаралар, шул исәптән Татарстан Республикасының белем бирү оешмаларында иҗтимагый чаралар, лекцияләр, мәгълүмати сәгатьләр | 12 декабрь | ТР ММ, ТР МһФМ, ТР ЯЭМ, «Татмедиа» РА, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 111. | «Тукучылыкның күпмилләтле сәнгате» халыкара симпозиумы («Төрки дөнья сәнгате» сериясеннән) | декабрь | ТР ММ, ТР ФА |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 112. | Туган телләр һәм халык бердәмлеге елына багышланган китаплар бастырып чыгару | декабрь | «Татмедиа» РА, ТКН (килешү буенча), КФУ (килешү буенча), ТР ФА, ТХА (килешү буенча) |
| 113. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар телләре һәм милли әдәбиятлар буенча республика предметлар олимпиадаларын үткәрү (аерым план буенча) | декабрь | ТР МһФМ |
| 114. | «Алтын Урда күзәтүе», «Крым тарихи күзәтүе», «Керәшен тарихи күзәтүе», «Тарихи этнология» кебек фәнни вакытлы журналлар бастырып чыгару | декабрь | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 115. | Белем бирү оешмалары өчен туган (чуваш, удмурт, мари, мордва) тел һәм әдәбият буенча укыту-методик комплектлар сатып алу | декабрь | ТР МһФМ |
| 116. | Белем бирү оешмаларын туган телләрдә матур әдәбият белән тәэмин итү | декабрь | ТР МһФМ |
| 117. | Татарстан Республикасының белем бирү оешмалары өчен Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак туган татар теле, туган татар әдәбияты һәм татар теле буенча яңа буын укыту-методик комплектларын сатып алу, дәреслекләр фондын яңарту | декабрь | ТР МһФМ |
| 118. | «Татарстан Республикасының рус традицион мәдәнияте» республика проектын гамәлгә ашыру | декабрь | ТР ММ, ТР РММБ (килешү буенча) |
| 119. | «Мудорвай» («Росточек») республика удмурт мәдәнияте конкурсы | декабрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), «ТР удмуртлары ММА» ТИО (килешү буенча) |
| 120. | Татарстан Республикасы халыкларының туган телләре буенча онлайн-дәресләр (социаль челтәрләрдә атналык «турыдан-туры эфирлар») | декабрь | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР МһФМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 121. | Татарстан халыклары Дуслык йорты вәкиллекләре һәм филиаллары өчен милли костюмнар һәм уен кораллары сатып алу | декабрь | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 122. | «Крым татарлары җырлары» фольклор җыентыгын әзерләү һәм бастырып чыгару | декабрь | Жиһанов ис. КДК (килешү буенча) |
| 123. | «Урта Идел буе рус булмаган православие халыкларының язма һәм әдәби традицияләрен формалаштыру һәм үстерү (XIX – XX гасыр башы)» монографиясен әзерләү һәм бастырып чыгару | декабрь | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 124. | «Татарларның урта гасыр язма мирасы» фәнни конференциясе (Сәйф Сарай тууының 700 еллыгына) | декабрь | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 125. | XVII – XX гасыр бөек татар мәгърифәтчеләренең педагогик мирасын өйрәнү һәм гомумиләштерү буенча халыкара көндезге-читтән торып конкурсын оештыру һәм үткәрү | декабрь | КФУ (килешү буенча) |
| 126. | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган чаралар (аерым план буенча) | ел дәвамында | ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 127. | Татарстан Республикасы халыкларының «Мин яратам сине, Татарстан» мәдәни күптөрлелеге һәм халыклар бердәмлеге турында иң яхшы видео-хикәяләргә республика видеороликлар конкурсы | ел дәвамында | ТР ИП (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 128. | «Күпкырлы Татарстан» күчмә фотокүргәзмәсе эше | ел дәвамында | ТР ЯЭМ, ТХЯА (килешү буенча), ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 129. | «Театр сезоннары» проекты (Идел буе төбәкләренең һөнәри милли театрларыннан төрле телләрдә постановкалар) | ел дәвамында | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча), ТР ҖҮО |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 130. | Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган күргәзмәләр оештыру (аерым план буенча) | ел дәвамында | ТР ММ, ТР ҖҮО (килешү буенча), ТР МБС (килешү буенча) |
| 131. | «Мәдәният һәм традицияләр теле – Татарстан халыклары бердәмлеге» чаралары комплексын үткәрү | ел дәвамында | ТР ММ, ТР РММБ (килешү буенча) |
| 132. | Билингваль һәм полилингваль белем бирү оешмалары укучылары өчен «Тамчы-шоу» халыкара фәнни-танып-белү, телевизион атналык конкурсын оештыру һәм үткәрү | ел дәвамында | КФУ (килешү буенча) |
| 133. | Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләрен берләштерү факторы булып торган тарихый даталарны популярлаштыру буенча фәнни тикшеренүләр оештыру, белем бирү проектларын әзерләү | ел дәвамында | Мәрҗани ис. Институт (килешү буенча) |
| 134. | Россия халыклары әсәрләренең татар һәм рус телләренә тәрҗемәләрен әзерләү һәм бастырып чыгару | ел дәвамында | ТР ММ, ТХА (килешү буенча), ТР ЯБ (килешү буенча) |
| 135. | 100tatarstan.ru бердәм челтәр мәгълүмат ресурсына мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм тулыландыру | ел дәвамында | «Татмедиа» РА, ТР ЦМ, ТБН (килешү буенча) |
| 136. | Татар, рус, мордва (эрзя, мокша), мари, удмурт, чуваш телләрендә «Аваз» рәсемле карточкалар җыелмасы | ел дәвамында | ТР МһФМ, ТМФ (килешү буенча) |
| 137. | «Сабантуй» мобиль кушымтасын (уенын) булдыру | ел дәвамында | ТР ММ, ККО (килешү буенча) |
| 138. | Татарстан Республикасы халыкларының милли телләре көннәрен үткәрү (аерым план буенча) | ел дәвамында | ТХА (килешү буенча), ХДЙ (килешү буенча) |
| 139. | Ютуб-канал өчен «Рус мәдәнияте кырлары» программаларын (алты программа) эшләү | ел дәвамында | ТР ММ, ТР РММБ (килешү буенча) |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| 140. | «Сабый» мультимедиа комплексы (татар һәм рус телләрендә) | ел дәвамында | ТР ММ, ККО (килешү буенча) |
| 141. | Татар, рус, мордва (эрзя, мокша), мари, удмурт, чуваш телләрендә «Уйна» өстәл уеннары | ел дәвамында | ТР ММ, ККО (килешү буенча) |
| 142. | «Милли сорау һәм җавап» проекты телетапшырулары циклын оештыру һәм булдыру | ел дәвамында | ТР ММ, «Татмедиа» РА, ТХА (килешү буенча) |
| 143. | Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елына багышланган радиотапшырулар, телепрограммалар, фильмнар циклын булдыру, шулай ук чараларны мәгълүмати яктырту | ел дәвамында | «Татмедиа» РА |
| 144. | Мәдәният учреждениеләренең рәсми социаль челтәрләрендә танылган мәдәният һәм сәнгать эшлеклеләре белән «турыдан-туры эфирлар» үткәрү | ел дәвамында | ТР ММ |
| 145. | Татар һәм рус телләрендә «Татар музыкасы гасыры» мультимедиа интернет-порталын гамәлгә ашыру | ел дәвамында | ТР ММ, ТР КБ (килешү буенча), Жиһанов ис. КДК (килешү буенча) |
| 146. | Казан шәһәрендә яңадан торгызылган Мәрьям Ана Казан иконасы Соборын ачу тантанасы | ел дәвамында | ТР Төзелеш министрлыгы, РПЧ ТМ (килешү буенча) |
| 147. | Казан шәһәрендә Җәмигъ мәчете төзелеше урынында истәлекле таш салу | ел дәвамында | ТР Төзелеш министрлыгы, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (килешү буенча), ТР МДН (килешү буенча) |
| 148. | «Сәлам», «Тумар» һәм «Казансу» фольклор коллективлары өчен милли киемнәр тегү | ел дәвамында | ТР ММ, Емельянов ис. МҮ (килешү буенча) |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТР ИҮА – Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгы;
ТХА – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
ТР ФА – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе;
БТК – «Бөтендөнья татар конгрессы» халыкара берлеге башкарма комитеты;
ТР ДС – Татарстан Республикасы Дәүләт Советы;
«Татаркино» ТР ДБМУ – «Татаркино» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;
ТР Архдәүлком – Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты;
ТР Турдәүлком – Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты;
«Бермәнчек» КДФА – «Бермәнчек» керәшен дәүләт фольклор ансамбле» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;
ХДЙ – «Татарстан халыклары Дуслык йорты» дәүләт бюджет учреждениесе;
ТР МДН – Үзәкләштерелгән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте;
Мәрҗани ис. Институт – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесе;
Жиһанов ис. КДК – югары белем бирүче «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;
КФУ – югары белем бирүче «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе;
Емельянов ис. МҮ – «Я.Е.Емельянов исемендәге Мәдәният үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;
ТХЯА – «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыкларының яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы;
ТР ЯЭМ – Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы;
ТР Урмхуҗмин – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы;
ТР Сәнәгать министрлыгы – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы;
ТР Авыл хуҗалыгы министрлыгы – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы;
ТР ЦМ – Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы;
ТР ММ – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы;
ТР МһФМ – Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы;

«Спадчына» ҖИО – Казан шәһәре белорусларының «Спадчына» («Мирас») җирле иҗтимагый оешмасы;
«Казан ш. бурятлары ММА» ҖИО – «Казан шәһәре бурятларының милли-мәдәни автономиясе» җирле иҗтимагый оешмасы;
«Казан ш. Поляклар» ҖИО – Казан шәһәренең Поляклар җирле иҗтимагый оешмасы;
ТР МР – Татарстан Республикасының муниципаль районы;
ТР Төзелеш министрлыгы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;
ТР ҖҮО – Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары;
ТР керәшеннәре ИО – Татарстан Республикасы керәшеннәренең иҗтимагый оешмасы;
ТР ИП – Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;
«Татмедиа» РА – Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы;
ТР РММБ – «Татарстан Республикасының Рус милли-мәдәни берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«Дагестан» ТИО – «Дагестан» Татарстан Республикасы Дагестан халыклары берләшмәсе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«ТР Яһүдлар ММА» ТИО – «Татарстан Республикасының яһүдлар милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«ТР марилары ММА» ТИО – «Татарстан Республикасы мариларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«ТР мордвалары ММА» ТИО – «Татарстан Республикасы мордваларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«ТР удмуртлары ММА» ТИО – «Татарстан Республикасы удмуртларының милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«Украина ММА» ТИО – Татарстан Республикасының «Берләштерелгән Украина милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
«ТР Чуваш ММА» ТИО – «Татарстан Республикасында Чуваш милли-мәдәни автономиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы;
ТР ЖБ – «Татарстан Республикасы Журналистлар берлеге – Иҗади берлек» төбәк иҗтимагый оешмасы;
ТР МБС – «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе;
ТР КБ – «Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге» төбәк иҗтимагый оешмасы;
ТР ЯБ – «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы (Иҗади берлек);
ТР ТЭБ – «Россия Федерациясенең Театр эшлеклеләре берлеге (Бөтенроссия театр җәмгыяте)» гомумроссия иҗтимагый оешмасы бүлекчәсе – Татарстан Республикасының Театр эшлеклеләре берлеге;
ТР РБ – «Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге» төбәк иҗади иҗтимагый оешмасы;
Татмәдресурсүзәге – «Мәдәният өлкәсендә инновацияләрне кертү һәм традицияләрне саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе;
Камал ис. ТДАТ – «Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

ТБН – «Татарстан балалар нәшрияты» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;
ТКН – «Татарстан китап нәшрияты» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе;
РПЧ ТМ – Рус православие чиркәвенең Татарстан митрополиясе (Мәскәү патриархаты);
ТМФ – «Татармультфильм» балалар анимация студиясе» автоном коммерциягә карамаган оешмасы;
Вәһапов ис. Фонд – Татарстан Республикасының Рәшит Вәһапов исемендәге Иҗтимагый татар мәдәнияте фонды.